ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

______________ с. Татарское Бурнашево ______________

«2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең 2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге бюджеты проектын ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән тикшерүдә катнашу хокукын үтәү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Бурнаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча халык алдында тыңлаулар уздырырга.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 04 декабрендә 14.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

Үткәрү урыны - Татар Бурнашы авылы, Совет урамы, 55 й.

авыл мәдәният йорты;

2.4. Фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерелергә мөмкин булган адрес - Татар Бурнашы авылы, Совет ур., 62 й.,

Бурнаш авыл җирлеге башлыгы Бурукин С.В.” (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2015 елның 30 ноябренә кадәр (тел 36-2-45).

3. Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджеты турында" гы карары проекты буенча гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. “гавами тыңлаулар” үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге советына халык тыңлаулары беркетмәсе, гавами тыңлаулар киңәше, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук (үзгәрешләр кертелгән очракта) эшләнеп беткән Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге бюджеты проектын 2016 елга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советы Карары проектын Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин